**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 3 апрелендәге 991 номерлы карары**

**Мәскәү районының Декабристлар урамындагы территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьяларына, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләрен гамәлдән чыккан дип тану турында»гы федераль законның 8 статьясына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 июлендәге 2783 номерлы карары белән расланган Декабристлар урамындагы территорияне планлаштыру проектына таянып, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 10 июнендәге 2422 номерлы «Декабристлар урамындагы җир кишәрлекләрен мәҗбүри алу турында»гы карары һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 2 ноябрендәге 4616 номерлы «Мәскәү районының Декабристлар урамындагы территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карарына туры китереп, **карар бирәм**:

1. Мәскәү районының Декабристлар урамындагы территорияне ызанлау проектын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә (А.П.Горбунов):

2.1. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә кую өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлекләренең кадастр номерлары турында мәгълүмат бирергә;

2.3. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

2.3.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмалар өчен аларга тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;

2.3.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә.

3. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләреннән кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләреннән кала, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 3 апрелендәге
991 номерлы карары белән
расланды

**Мәскәү районының Декабристлар урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Мәскәү районының Декабристлар урамындагы территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләре теркәлгән территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап).

III. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап).

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлекләре хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырып чыгарылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Ызанлау проекты Декабристлар урамында Казан шәһәренең торак булмаган төзелеш территориясе өчен эшләнде, аңа карата Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 февралендәге 558 номерлы карары нигезендә территорияне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла.

Мәскәү районының Декабристлар урамындагы территорияне ызанлау проекты җирле әһәмияттәге объект – территориясе комплексы төзекләндерелгән һәм яшелләндерелгән сквер урнаштыру максатыннан эшләнә. Аның чикләре Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 июлендәге 2783 номерлы карары белән расланган Декабристлар урамындагы территорияне

планлаштыру проекты белән билгеләнгән.

Ызанлау проекты территориясе мәйданы – 7643 кв.м.

Җирле әһәмияттәге объект – сквер урнаштыру максатыннан Казан шәһәренең торак булмаган төзелеш территориясен комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыру өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 10 июнендәге 2422 номерлы карары белән Казан шәһәре, Декабристлар урамы адресы буенча урнашкан комплекслы үсеш территориясе чикләрендәге җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын муниципаль ихтыяҗлар өчен сатып алу юлы белән мәҗбүри алу каралган.

Комплекслы үстерелергә тиешле һәм Казан шәһәре, Декабристлар урамы адресы буенча урнашкан Казан шәһәренең торак булмаган төзелеш территориясе чикләренең урнашу урыны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 февралендәге 558 номерлы карары белән билгеләнгән.

Казан шәһәренең торак булмаган төзелеш территориясен комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен мәҗбүри алынырга тиешле һәм Казан шәһәре, Декабристлар урамы адресы буенча урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары исемлеге, алар турында мәгълүмат таблицада китерелгән.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 65 статьясы нигезендә әлеге җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары мәҗбүри алынырга мөмкин.

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 февралендәге 558 номерлы «Казан шәһәре, Декабристлар урамы адресы буенча урнашкан торак булмаган төзелеш территориясен комплекслы үстерү турында»гы карары белән 16:50:100419:98, 16:50:100419:110, 16:50:100419:1163, 16:50:100419:1191, 16:50:100419:1200, 16:50:100419:1201, 16:50:000000:10965 кадастр номерлы капиталь төзелеш объектларын сүтү каралган.

Территорияләрне Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 июлендәге 2783 номерлы карары белән расланган Декабристлар урамындагы территорияне планлаштыру проектына туры китерү максатыннан ызанлау проекты җир кишәрлеген ике этапта ясауны күздә тота.

Җир кишәрлеген ясау 6:50:100419:23, 16:50:100419:61, 16:50:100419:1160, 16:50:100419:19, 16:50:100419:1159, 16:50:100419:1155, 16:50:100419:1291, 16:50:100419:1255, 16:50:100419:1154, 16:50:100419:1241, 16:50:100419:1162, 16:50:100419:70, 16:50:100419:69, 16:50:100419:20, 16:50:100419:1618, 16:50:100419:1619 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә карата рөхсәт ителгән файдалану төрен «мәдәният һәм ял парклары (3.6.2)» дип билгеләгәннән соң һәм

Документ создан в электронной форме. № 48223-ПСП от 23.04.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 5 из 22. Страница создана: 23.04.2025 11:39
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

аларга карата Казан шәһәренең муниципаль милек хокукы булган очракта мөмкин.

Ясала торган җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы белән билгеләнгән таләпләр үтәлгән.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Таблица

| **№ т/б** | **Җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Җир кишәрлеге мәйданы, кв.м** | **Җир кишәрлегендә урнашкан капиталь төзелеш объектының кадастр номеры** | **Капиталь төзелеш объекты адресы** | **Капиталь төзелеш объекты мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:100419:1154 | Сәүдә павильоннары өчен | 206,0 | 16:50:100419:1168 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131в йорт, 1 бина | 37,5 |
| | | | | 16:50:100419:1169 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131в йорт, 2 бина | 27,5 |
| | | | | 16:50:100419:1170 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131в йорт, 3, 4 биналар | 55,0 |
| 2 | 16:50:100419:1155 | Сәүдә объекты | 58,0 | 16:50:100419:1189 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131в йорт, 10 бина | 31,5 |
| 3 | 16:50:100419:1159 | Чәчәкләр сату буенча сәүдә павильоны урнаштыру | 221,0 | 16:50:100419:1201 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 133Е йорт | 348,0 |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | 16:50:100419:1160 | Чәчәкләр сату буенча сәүдә павильоны урнаштыру | 68,0 | 16:50:100419:111 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 133В йорт | 40,5 |
| 5 | 16:50:100419:1162 | Административ офислар; финанс оешмалары биналары (бүлмәләре); сәүдә объектлары; җәмәгать туклануы объектлары; даруханә учреждениеләре; җиңел автомобильләрне кую урыннары | 342,0 | 16:50:100419:1190 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү районы, Декабристлар урамы, 131А йорт | 109,1 |
| 6 | 16:50:100419:1241 | Административ офислар; мәгълүмат бирү буенча хезмәтләр күрсәтә торган редакция һәм нәшрият оешмалары, реклама агентлыклары биналары (бүлмәләре); хокукый хезмәтләр күрсәтә торган оешмалар биналары (бүлмәләре); финанс оешмалары биналары (бүлмәләре); базарлардан тыш, сәүдә объектлары; җәмәгать туклануы объектлары; көнкүреш | 273,0 | 16:50:100419:1305 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131А йорт, 1, 1а, 1б, 2, 2а, 2б, 7 биналар | 78,1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | хезмәте күрсәтү объектлары, мәдәният һәм сәнгать объектлары; күңел ачу билгеләнешендәге объектлар (ял итү объектлары); спорт объектлары; даруханә учреждениеләре; кунакханә сервисы объектлары (урнаштыру чаралары) | | | | |
| 7 | 16:50:100419:1255 | Сәүдә объекты | 184,0 | 16:50:100419:1188 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131в йорт, 5 бина | 31,1 |
| | | | | 16:50:100419:1194 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131в йорт, 6, 6а, 6б, 6в, 6г, 6д, 6е, 6ж биналар | 102,2 |
| 8 | 16:50:100419:1291 | Кафе бинасы өчен (код 4.6) | 404,0 | 16:50:100419:1200 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131Д йорт | 367,8 |
| 9 | 16:50:100419:19 | «Чәчәкләр» сәүдә павильоны өчен | 103,0 | 16:50:000000:10965 | Татарстан Республикасы (Татарстан), Казан шәһәре, | 282,7 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Декабристлар урамы | |
| 10 | 16:50:100419:20 | Чәчәкләр һәм азык-төлек сату буенча блоклап төзелгән сәүдә павильоннары урнаштыру өчен | 740,0 | 16:50:100419:110 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 133д йорт | 612,0 |
| 11 | 16:50:100419:23 | Сәүдә павильоны өчен | 16,38 | 16:50:100419:1163 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 133ж йорт | 13,1 |
| 12 | 16:50:100419:61 | Сәүдә павильоны өчен | 19,0 | 16:50:100419:1191 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 133 номерлы бина янында | 17,1 |
| 13 | 16:50:100419:69 | Сәүдә павильоны өчен | 120,0 | 16:50:100419:98 | Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 131б йорт | 103,3 |

1 нче этап.

Беренче этапта түбәндәге җир кишәрлекләре ясала:

- мәйданы 822 кв.м булган :ЗУ1 – Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункт нигезендә беренчел җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен «мәдәният һәм ял парклары (3.6.2)» дип билгеләп, 16:50:100419:20 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлеген һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү юлы белән;

- мәйданы 4218 кв.м булган :ЗУ2 – Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункт нигезендә беренчел җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрен «мәдәният һәм ял парклары (3.6.2)» дип билгеләп, 16:50:100419:1618, 16:50:100419:1619 кадастр номерлы беренчел җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү юлы белән.

2 нче этап.

Икенче этапта 1 нче этапта ясалган :ЗУ1 һәм :ЗУ2 беренчел җир кишәрлекләрен, 16:50:100419:70, 16:50:100419:19, 16:50:100419:23, 16:50:100419:61, 16:50:100419:1160, 16:50:100419:1159, 16:50:100419:1155, 16:50:100419:1291, 16:50:100419:1255, 16:50:100419:1154, 16:50:100419:1241, 16:50:100419:1162, 16:50:100419:69 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне яңадан бүлү юлы белән мәйданы 7417 кв.м булган :ЗУ3 ясала. Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункт нигезендә аның өчен билгеләнгән төп рөхсәт ителгән файдалану төре – «мәдәният һәм ял парклары (3.6.2)».

1 нче һәм 2 нче этапларда ясала торган, шартлы номерлары :ЗУ1, :ЗУ2, :ЗУ3 булган җир кишәрлекләре гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (территорияләр) булып санала.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 36 статьясындагы 4 пункт нигезендә гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә шәһәр төзелеше регламентлары йогынтысы кагылмый.

Әлеге ызанлау проекты белән ясала торган җир кишәрлекләре график өлештә күрсәтелгән.

Җир кишәрлекләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:


- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен сузу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, эксплуатацияләүче

Документ создан в электронной форме. № 48223-ПСП от 23.04.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 11 из 22. Страница создана: 23.04.2025 11:39
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.

## II. Территорияне ызанлау сызымы (1 нче этап)




Масштаб 1:500

## Шартлы билгеләр

| | |
|---|---|
| | Гамәлдәге кызыл линияләр |
| | Ызанлау проекты территориясе чикләре |
| | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләре |
| | Кадастр кварталы чикләре |
| | Территориаль зона чикләре |
| | Гамәлдәге җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары чикләре |
| 16:50:100419:1159 | Исәпкә алынган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының кадастр номерлары |
| 16:50:100419 | Кадастр кварталының кадастр номеры |
| 16:50-7.1198 | Территориаль зоналарның реестр номерлары |
| | Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән (исәпкә алынган) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре |
| 16:50-6.5739 | Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарның реестр (исәпкә алу) номерлары |
| н1 | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| н1 | Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| :ЗУ1, :ЗУ2 | Ясала торган җир кишәрлекләренең билгеләнеше |
| | Беренчел җир кишәрлекләренең билгеләнеше |

# III. Территорияне ызанлау сызымы (2 нче этап)




Масштаб 1:500

## Шартлы билгеләр

| Билге | Аңлатма |
|---|---|
| (кызыл сызык) | Гамәлдәге кызыл линияләр |
| (зәңгәрсу өзек сызык) | Ызанлау проекты территориясе чикләре |
| (зәңгәр сызык) | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләре |
| (алсу сызык) | Кадастр кварталы чикләре |
| (яшел өзек сызык) | Территориаль зона чикләре |
| (кара сызык) | Гамәлдәге җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары чикләре |
| 16:50:100419:1159 | Исәпкә алынган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының кадастр номерлары |
| 16:50:100419 | Кадастр кварталының кадастр номеры |
| 16:50-7.1198 | Территориаль зоналарның реестр номерлары |
| (яшел турыпочмак) | Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән (исәпкә алынган) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре |
| 16:50-6.5739 | Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарның реестр (исәпкә алу) номерлары |
| ● н1 | Ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| ● н1 | Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары номерлары |
| (сары турыпочмак) | Беренчел җир кишәрлекләренең билгеләнеше |
| :ЗУ3 | Ясала торган җир кишәрлегенең билгеләнеше |

Документ создан в электронной форме. № 48223-ПСП от 23.04.2025. Исполнитель: Переводчики
Страница 22 из 22. Страница создана: 23.04.2025 11:39
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН